Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Башкарма комитетының «җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 19 сентябрендәге 14 номерлы карары

"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында "Федераль законга һәм" Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматка үтемлелекне тәэмин итү турында "Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Әлмәндәр авыл җирлеге» җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматка үтемлелекне тәэмин итү хакында» 2014 елның 01 февралендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада

1.8 пунктны төшереп калдырырга;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1.Апас муниципаль районына керүче җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2.Җирле үзидарә органнары 8-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән һәм аларның эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүмат белән беррәттән рәсми сайтта 8-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып үз эшчәнлеге турында башка мәгълүмат урнаштыра алалар.

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.3.Җирле үзидарә органнары тарафыннан рәсми сайтка урнаштырыла торган һәркем файдалана алырлык мәгълүмат составы, шул исәптән ачык мәгълүматлар рәвешендә урнаштырыла торган мәгълүмат (8-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 7.1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматтан тыш), җирлек башкарма комитеты тарафыннан раслана торган мәгълүмат исемлеге белән билгеләнә»;

2.5-2.7.4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматнең рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Җирлек башлыгы Р.Х.Җәләлиев